**РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН**
**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ**
**АЛЬКЕЕВСКОГО**
**МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА**
422870, С.Базарные Матаки,
ул.С.Крайнова,д.58

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**ӘЛКИ**
**МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ**
**БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**
422870, ТР Базарлы Матак авылы,
С.Крайнов ур.,58

Телефон: (84346) 20-0-26, факс: (84346) 21-7-60. E-mail: alkay.ispolkom@tatar.ru сайт: www.alkeevskiy.tatarstan.ru.

# ПОСТАНОВЛЕНИЕ
# КАРАРЫ

*2020 елның 1 сентябре* *313№*

**Югары квалификацияле спортчылар әзерләгән өчен тренерларга, адаптив физик тәрбия буенча тренерларга, тренерларга (шул исәптән өлкәннәргә), шулай ук спорт резервын әзерләүне гамәлгә ашыручы муниципаль физик тәрбия-спорт оешмаларында эшләүче спортчы-инструкторларга һәм спортчыларга ярышларда алган нәтиҗәләре өчен бүләкләү Тәртибен раслау турында**

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2018 елның 25 сентябрендәге «Татарстан Республикасында спорт резервын әзерләүне гамәлгә ашыручы дәүләт физкультура спорт оешмалары хезмәткәрләренә хезмәт өчен түләү шартлары турында»гы 853 номерлы Карары, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2018 елның 29 декабрендәге «Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре бюджетларына югары квалификацияле спортчылар әзерләгән өчен тренерларны, шулай ук спорт резервын әзерләүне гамәлгә ашыручы муниципаль физик тәрбия - спорт оешмаларында эшләүче спортчыларны бүләкләү өчен Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидияләр бирү тәртибен раслау турында»гы 1258 номерлы Карары, Татарстан Республикасы спорт министрлыгының 2019 елның 17 маендагы 155 номерлы боерыгы нигезендә

**карар бирәм:**

1.Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районында югары квалификацияле спортчылар әзерләгән өчен адаптив физик культура буенча тренерларга, тренерларга (шул исәптән өлкәннәргә), шулай ук спорт резервын әзерләүне гамәлгә ашыручы муниципаль физкультура-спорт оешмаларында эшләүче спортчы-инструкторларга һәм спортчыларга ярышларда алган нәтиҗәләре өчен Татарстан Республикасы бюджетыннан бирелә торган акчалар исәбеннән бүләкләү Тәртибен расларга( Кушымта)

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районының рәсми сайтында һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында урнаштырырга.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Әлки муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең социаль мәсьәләләр буенча урынбасарына йөкләргә.

**Башкарма комитет җитәкчесе:** **И.В.Юсупов**

Татарстан Республикасы Әлки
муниципаль районы Башкарма
комитетының
______елның ___ ___________
_______ номерлы карарына
кушымта

**Югары квалификацияле спортчылар әзерләгән өчен тренерларга, адаптив физик тәрбия буенча тренерларга, (шул исәптән өлкәннәргә), шулай ук спорт резервын әзерләүне гамәлгә ашыручы муниципаль физик тәрбия-спорт оешмаларында эшләүче спортчы-инструкторларга һәм спортчыларга ярышларда алган нәтиҗәләре өчен бүләкләү Тәртибе**

1. Әлеге Тәртип Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районында югары квалификацияле спортчылар әзерләгән өчен адаптив физик культура буенча тренерларга, тренерларга (шул исәптән өлкәннәргә), шулай ук спорт резервын әзерләүне гамәлгә ашыручы муниципаль физик тәрбия-спорт оешмаларында эшләүче спортчы-инструкторларга һәм спортчыларга ярышларда алган нәтиҗәләре өчен Татарстан Республикасы бюджетыннан бирелә торган акчалар исәбеннән бүләкләүне билгели.

2. Тренерларга, тренер-укытучыларга, шулай ук спортчы-инструкторларга һәм спортчыларга ярышларда алынган нәтиҗәләр өчен бүләкләү әлеге Тәртипнең 1 пунктында күрсәтелгән максатларга Татарстан Республикасы бюджетында Татарстан Республикасы Спорт министрлыгына тиешле финанс елына каралган акчалар хисабына башкарыла.

3. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2018 елның 25 сентябрендәге «Татарстан Республикасында спорт резервын әзерләүне гамәлгә ашыручы дәүләт физик тәрбия - спорт оешмалары хезмәткәрләренә хезмәт өчен түләү шартлары турында»гы 853 номерлы Карары нигезендә югары квалификацияле спортчыларны әзерләгән өчен, шулай ук ярышларда алган нәтиҗәләр өчен (алга таба - бүләк) түләү билгеләнә:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2018 елның 25 сентябрендәге «Татарстан Республикасында спорт резервын әзерләүне гамәлгә ашыручы дәүләт физкультура спорт оешмалары хезмәткәрләренә хезмәт өчен түләү шартлары турында»гы 853 номерлы карары белән расланган «Татарстан Республикасында спорт резервын әзерләүне гамәлгә ашыручы дәүләт физкультура спорт оешмалары хезмәткәрләренә хезмәт өчен түләү шартлары турында»гы Нигезләмәнең 7 нче таблицасы нигезендә муниципаль физик тәрбия - спорт оешмаларында эшләүче һәм спорт резервын әзерләүче тренерларга, адаптив физик тәрбия буенча тренер-укытучыларга (шул исәптән өлкәннәргә);

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2018 елның 25

сентябрендәге «Татарстан Республикасында спорт резервын әзерләүне гамәлгә ашыручы дәүләт физкультура спорт оешмалары хезмәткәрләренә хезмәт өчен түләү шартлары турында»гы 853 номерлы карары белән расланган «Татарстан Республикасында спорт резервын әзерләүне гамәлгә ашыручы дәүләт физкультура спорт оешмалары хезмәткәрләренә хезмәт өчен түләү шартлары турында»гы Нигезләмәнең 16 нчы таблицасы нигезендә спорт резервын әзерләүне гамәлгә ашыручы муниципаль физик тәрбия - спорт оешмаларында эшләүче спортчы- инструкторларга һәм спортчыларга.

4. Бүләк күләме тәрбияләнүченең спорт нәтиҗәсе нигезендә билгеләнә һәм ярышларны оештыручы билгели торган судьялар комиссиясе тарафыннан бәяләнә, спортчы күрсәткән нәтиҗәдән соң, бер календарь ел дәвамында ярышлар протоколын төзү юлы белән рәсмиләштерелә.

Әгәр бер календарь ел узгач спортчы ирешелгән күрсәткечләрен сакласа, хезмәткә түләү күләме билгеләнә:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2018 елның 25 сентябрендәге «Татарстан Республикасында спорт резервын әзерләүне гамәлгә ашыручы дәүләт физкультура спорт оешмалары хезмәткәрләренә хезмәт өчен түләү шартлары турында»гы 853 номерлы карары белән расланган «Татарстан Республикасында спорт резервын әзерләүне гамәлгә ашыручы дәүләт физкультура спорт оешмалары хезмәткәрләренә хезмәт өчен түләү шартлары турында»гы Нигезләмәнең 1 нче һәм 4 нче таблицалары нигезендә Татарстан Республикасында муниципаль физик тәрбия - спорт оешмаларында эшләүче һәм спорт резервын әзерләүче тренерларга, адаптив физик тәрбия буенча тренер-укытучыларга (шул исәптән өлкәннәргә);

5. Ярышларда югары нәтиҗәләргә ирешкән югары квалификацияле спортчы әзерләгән өчен бүләкләү процентлар суммасыннан, һәр дәрәҗәдәге ярышларда иң яхшы нәтиҗә өчен (спортчының сигез ярышларыннан артмаган) әгәр мондый ярышларда медаль комплектлары уйнатылса, программа төрләрендә спортчы һәм команда күрсәткән иң яхшы нәтиҗә өчен билгеләнә.

Татарстан Республикасында муниципаль физик тәрбия - спорт оешмаларында эшләүче һәм спорт резервын әзерләүче тренерларга, адаптив физик тәрбия буенча тренер-укытучыларга (шул исәптән өлкәннәргә), спортчыларга, агымдагы елда Россия Федерациясе Спорт министрлыгының (II өлеш) төбәкара, бөтенроссия һәм халыкара физик тәрбия чаралары һәм спорт чараларының бердәм календарь планына һәм Татарстан Республикасы спорт-массакүләм һәм физик тәрбия чараларының календарь планына (Татарстан Республикасы чемпионатлары өлешендә) кертелгән ярышларда алынган урын нигезендә түләнә.

Ярышларда адаптив физик тәрбия буенча югары нәтиҗәләргә ирешкән югары квалификацияле спортчы әзерләгән өчен тренерларга, тренер-

укытучыларга (шул исәптән өлкәннәргә) бүләкләүләр түләнә торган халыкара һәм бөтенроссия ярышлары исемлеге Россия Федерациясе Спорт министрлыгының төбәкара, бөтенроссия һәм халыкара физик тәрбия чаралары һәм спорт чараларының бердәм календарь планының II өлеше белән билгеләнә.

6. Төп тренер белән бер үк вакытта эшләү шарты белән югары квалификацияле спортчы әзерләүгә өстәмә рәвештә җәлеп ителә торган адаптив физик тәрбия буенча тренер-укытучылар (шул исәптән өлкәннәр) өчен югары квалификацияле спортчы әзерләү хезмәте өчен түләү нормативлары, төп тренерга түләнгән кебек үк эш урыны буенча шул ук шартларда һәм спортчыларның атналык эш режимыннан пропорциональ рәвештә эшләнгән вакыт күләмендә билгеләнә.

7. Спортчы-инструктор һәм спортчыларның хезмәт өчен түләү нормативы күләме рәсми халыкара һәм бөтенроссия ярышларында ирешелгән нәтиҗәләр өчен бер календарь ел дәвамында спортчылар-инструкторлар, спортчылар күрсәткән нәтиҗәгә ирешкән вакыттан алып ярыш беркетмәсе күчермәсе нигезендә билгеләнә.

8. Спортчы инструкторларның һәм спортчыларның хезмәте өчен түләү нормативы рәсми халыкара һәм бөтенроссия ярышларында яулаган эш урыны нигезендә ирешелгән нәтиҗәләр өчен, бүләкләү процентлар суммасыннан, һәр дәрәҗәдәге ярышларда иң яхшы нәтиҗә өчен (спортчының сигез ярышларыннан артмаган) әгәр мондый ярышларда медаль комплектлары уйнатылса, программа төрләрендә спортчы күрсәткән иң яхшы нәтиҗә өчен билгеләнә.

9. Нәтиҗә өчен акчалата түләүләр адаптив физик тәрбия буенча тренерларга, тренер-укытучыларга (шул исәптән өлкәннәргә) әгәр программа рәвешендә катнашучылар саны (пар, төркемнәр, экипажлар, спортчылар командалары) саны түбәндәгечә булган очракта билгеләнә:

кимендә 6 (инвалидлар һәм сәламәтлек мөмкинлекләре чикләнгән затлар шөгыльләнә торган спорт төрләреннән тыш);

кимендә 6 (инвалидлар һәм сәламәтлек мөмкинлекләре чикләнгән затлар шөгыльләнә торган спорт төрләре);

Югары квалификацияле спортчылар әзерләгән өчен тренерларга, тренерлар-укытучыларга (шул исәптән өлкәннәргә) бүләкләүләр спортчы белән эшләү вакыты ул ярышларда нәтиҗәне алганчы кимендә ике ел эшләгән очракта билгеләнә.

Югары квалификацияле спортчыларны әзерләгән өчен спорт әзерлеге программаларын гамәлгә ашыруда бергә эшләүнең бригада ысулы белән катнашучы тренерларга, тренер-укытучыларга (шул исәптән өлкәннәргә) акчалата түләү директор приказы белән билгеләнә.

10. Бүләкләү күләме күнегүләр йөкләнеше күләменә бәйле түгел һәм билгеләнә:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2018 елның 25 сентябрендәге «Татарстан Республикасында спорт резервын әзерләүне гамәлгә ашыручы дәүләт физкультура спорт оешмалары хезмәткәрләренә хезмәт өчен түләү шартлары турында»гы 853 номерлы карары белән расланган нормативлар нигезендә Татарстан Республикасында муниципаль физик тәрбия - спорт оешмаларында эшләүче һәм спорт резервын әзерләүче тренерларга, адаптив физик тәрбия буенча тренер-укытучыларга (шул исәптән өлкәннәргә), спортчы - инспекторларга, спортчыларга.

11. Бүләк Татарстан Республикасы Спорт министрлыгы карары нигезендә бирелә.

12. Тренерларга, адаптив физик тәрбия буенча тренер-укытучыларга (шул исәптән өлкәннәргә), спортчы - инспекторларга һәм спортчыларга бүләкләү төп эш урыны буенча гына билгеләнә ( адаптивлы спорт мәктәпләрдән тыш).

13. Акчалата түләү оешма җитәкчесе боерыгы нигезендә ай саен башкарыла.

14. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2018 елның 20 февралендәге «Халыкара һәм бөтенроссия спорт ярышларында югары казанышлар өчен спортчылар һәм тренерларга дәүләт ярдәме турында» 98 номерлы карары нигезендә Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2018 елның 25 сентябрендәге «Татарстан Республикасында спорт резервын әзерләүне гамәлгә ашыручы дәүләт физкультура спорт оешмалары хезмәткәрләренә хезмәт өчен түләү шартлары турында»гы 853 номерлы карары белән билгеләнгән югары квалификацияле спортчы әзерләгән өчен тренерларга, тренер-укытучыларга (шул исәптән өлкәннәргә) һәм ярышларда югары нәтиҗәләргә ирешкән спортчыларга, спортчылар-инструкторларга шундый ук нәтиҗәләр өчен түләү билгеләүне юкка чыгара.